**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«ШИЛНӨБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

«8» ноябрь, 2019 ел а.Шилнөбаш № 36

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Шилнөбаш авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1 маддәсе, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Тукай муниципаль районы Шилнөбаш авыл җирлеге уставы нигезендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Шилнөбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы

КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Шилнөбаш авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәне расларга.
2. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Шилнөбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2018 елның 24 сентября 29/4 санлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Шилнөбаш авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә» үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып халыкка игълан итәргә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.
5. Әлеге карар рәсми игълан ителгәннән соң үз көченә керә.
6. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Шилнөбаш авыл җирлеге Башлыгына йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет рәисе О.А. Гончарова